СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

4 апрель, 1997 ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 37 (8049) | Бәясе билгеләнгәнчә

## НУРБ йөзен үзгәртте

**Норлат разведка бораулавы идарәсе 1 нче апрельдән чикләнгән җаваплылыктагы «Татнефть - Норлатнефтьразведка» җәмгыяте итеп үзгәртелде.**

Исемгә килгәндә, ул предприятиенең тарихи асылын чагылдыра. Шуңа да коллектив аны үзе сайлап алган.

Ә үзгәрешнең җисеменә килгәндә, предприятие директоры А.Н.Насолдин әйтүенчә, ул «Татнефть»не акционерлаштыру этабында ук каралган була, НУРБга бүлендек предприятие статусы бирү ике як өчен дә отышлырак булыр дип исәпләнелә. Шул рәвешчә, «Татнефть - Норлатнефтьразведка» «Татнефть» АҖнең хезмәт күрсәтүче сервис предприятие булып калачак. Аның төп максаты, әлбәттә, максималь табыш китерүдән гыйбарәт. Ә менә эш объектларын, заказчыларны табуда, сайлауда, килешүләр төзүдә предприятие иректе. Гомумән, Анатолий Степанович структур үзгәрешләрне уңайга юрый: «Һәртөрле үзгәреш - ул алга таба хәрәкәт итү», дигән фикердә тора һәм коллектив белән бергә шуңа омтыла.

Предприятиедә реорганизациягә бәйле рәвештә кыскартулар көтелми. Элек Алабуга разведка - бораулау идарәсе белән бер предприятиене тәшкил иткән булсалар, хәзер алар белән туганлык аралары өзелде (анда да шундый ук үзгәрешләр булды). Предприятиедә якынча 100әр кешелек 7 бригада эшли, аларның 5се үзебездә һәм күрше районнарда булса, 2се Ульяновск өлкәсендә бораулый. Күптән түгел Самара өлкәсе белән дә килешү төзелде, озакламый 8 нче бригада ызандаш өлкә җирләреннән нефть ятмалары эзләячәк. Әлегә коллектив та шул ук составта, матди база да шул хәлдә.

Ә проблемалар хакында сүз кузгату әлегә мәгънәсез. Директор әйтүенчә, яңа предприятие яшәешенең беренче этабында дияргә мөмкин, һәммәсе дә үз урынына басарга тиеш, ди ул оптимистларча.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

## Хезмәтләре белән мактаулылар

### Һаман юлда

Александр Кириллов - «Мамык» крестьян хуҗалыклары ассоциациясенең иң ышанычлы шоферларының берсе. Шуңа күрә аңа эшнең дә һәрчак иң җаваплысын тапшыралар. Әле менә кыш буе Төрнәс спирт заводыннан барда ташыды. Аның гаебе белән бер генә рейс та өзелмәде.

Хәер, Александр Порфирьевич үзенә йөкләнгән теләсә нинди нарядны төгәл үтәргә күнеккән. Җәй ул басудан ындыр табагына ашлык ташый, шул арада элеваторга барып кайтырга да өлгерә. Терлек азыгы хәзерләү чорында да тулы көченә хезмәт куя ул, ерак рейсларга да йөри.

Александр Порфирьевичның шоферлык стажы 30 еллап җыела. Соңгы 10 елын бер машинада эшли ул. Яңа килеш кабул итеп алган «КамАЗы»да карап тоткач, әле дә яңага биргесез.



**Рәсемдә: шофёр А.П.Кириллов.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

### Мактаулы исемнәр

Нефть промышленностена транспорт хезмәте күрсәтүдәге уңышлары өчен «Татнефть» акционерлык җәмгыяте хезмәткәрләре: «Норлатнефть» идарәсе юл цехының асфальт җәюче машинисты **Голубев Александр Николаевичка**, Норлат ятмаларны разведка - бораулау идарәсе автотрактор цехы башлыгы **Показаньев Владимир Андреевичка** «Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Президенты Указы белән Норлат разведка бораулавы идарәсе профсоюз комитеты рәисе **Галиулла Шәйхетдин улы Сөләймановка** «Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе» дигән мактаулы исем бирелде.

### Иртәгә - өмә

***Норлат шәһәр үзидарәСоветы карары белән 5 нче апрельдә шәһәрне төзекләндерү һәм санитар чистарту буенча шәһәркүләм шимбә өмәсе игълан ителә.***

## Матбугат - 97
## «Дуслык»ка льготалы язылу!

**Хөрмәтле укучыларыбыз!**

1 апрельдән элемтә бүлекләренә килеп, матбугат басмаларына язылганда без Сезнең иң беренче бланкларны «Дуслык»ка дип тутырачагыгызга шикләнмибез. Шунысын да әйтик, редакция, район элемтә узелы белән килешеп, район газетасына ярты елга язылу бәясен элеккечә, ягъни 23.400 сум көенә калдырды. Бу хакта үзегез күргән - белгәннәрнең моңарчы безнең газетаны алдырмаганнарына да җиткерерсез дип уйлыйбыз.

**Һәм, иң мөһиме!**

**Апрельнең 1еннән 10сына кадәр «Дуслык» («Дружба», «Туслах») газеталарына льготалы бәягә, ягъни 16.200 сумга гына язылып калырга мөмкин.**

**Атнасына өч көн чыга торган матбугат органына язылуның шуннан да арзанрак бәясенең әле беркайда да булганы юк. Шулай булгач, нибары 16.200 сум акчагызны кызганмыйча, район газетасына язылып куйсагыз, ел ахырына кадәр райондагы хәлләр турында хәбәрдар булып торачагыгыз көн кебек ачык - анысына без ышандырабыз.**

**Дус булыйк, «Дуслык»лы булыйк!**

## «Родина»да - яңа рәис

31 мартта «Родина» крестьян хуҗалыклары ассоциациясе членнарының гомуми җыелышы булды. Җыелыш Н.Е.Евлампьевның аны хуҗалык рәисе вазифаларыннан азат итү турындагы гаризасын канәгатьләндерде. Ассоциация рәисе итеп бертавыштан шушы авыл егете - моңарчы хуҗалыкның баш инженеры булып эшләгән Хасибулла Хәбибулла улы Хәмидуллин сайланды.

Җыелышта чыгыш ясаучылар элеккеге җитәкченең үз вазифасын намус кушканча башкарганлыгын билгеләп аңа рәхмәтле калуларын әйттеләр, яңа сайланган рәискә бу җаваплы постта уңышлы эшләү, хәзерге катлаулы икътисадый - финанс шартларында хуҗалыкта эшне ипле алып баруда кулларыннан килгән ярдәмне, барьяклы булышлык һәм теләктәшлек күрсәтәчәкләрен белдерделәр. Яңа җитәкче үз чиратында авылдашларына аңа олы ышаныч күрсәтүләре өчен рәхмәт әйтеп, аларны хуҗалыкның моңарчы ирешелгән уңышларын тотрыклы итү, хәлне уңайлату хакына алга таба да кулга кул тотынып эшләргә чакырды.

Җыелышта район хакимияте аппараты җитәкчесе Ф.М.Галимов катнашты һәм чыгыш ясады. Ул бүген республикада һәм районда бара торган киң колачлы реформаларның төп максаты һәм асыл хасияте турында сөйләп, родиналыларның бу зур эштә һичшиксез үз сүзләрен әйтәчәкләренә ышаныч белдерде, аларны хуҗалыкның һәр тармагында чын хуҗаларча эш итеп, хәзерге катлаулы шартларда да югалып калмыйча, кыенлыкларны бердәмлек һәм туплангалык, намуслы хезмәт белән җиңү хакына җиң сызганып эшләргә чакырды.

**Рәсми хроника**

## Мөдир алышынды

Октябрь районының хезмәт һәм эш белән мәшгульлек бюросы мөдире Роза Абдулла кызы Әхмәтсәгыйрова пенсиягә китү сәбәпле вазифаларыннан азат ителде. Бюро мөдире итеп Наил Атаулла улы Хәйбуллин билгеләнде.

## АЛДЫНГЫЛАР ТӘҖРИБӘСЕНӘ ИЯРЕП

### Безнең интервью

***Соңгы бер ельярым вакыт эчендә Якты Күл авылы зур үзгәрешләр кичерде. Элеккеге «Рассвет» совхозы составында булган авыл башка чыгып мөстәкыйль хуҗалык булып яши башлаган гына иде, инде күптән түгел ул яңа оешкан «Норлат» агрофирмасы составына керде. Билгеле инде, хуҗалыкның проблемалары да байтак. Шул ук вакытта вак кына уңышлары да күзгә бәрелеп торырлык. Әйтик, хуҗалыкның сөтчелек тармагында соңгы вакытта зур алга китеш бар. Ассоциация рәисе В.В.САТДАРОВ белән дә шул хакта сөйләшәбез.***

- Әйе, бүген һәр сыердан савылган сөт 11 килограмм тәшкил итә, һәм бу - узган елның шул чорындагыдан 5,1 килограммга күбрәк. Моңа нәрсә бәрабаренә ирешелде соң? Иң элек маллар асрау технологиясенә яңача, карау нәтиҗәсендә диясем килә минем. Балтач, Мамадыш, Биектау районнарының алдынгы хуҗалыкларында булып, аларда маллар асрау тәҗрибәсен өйрәнү терлекчелек тармагына икенче төрле карарга мәҗбүр итте безне. Савым сыерларны цех структурасы буенча асрауга зур игътибар бирәбез быел. Бу - барлык төр малга индивидуаль якын килергә, аларны аерым рацион буенча ашатырга мөмкинлек бирә.

**- Ашату дигәннән, азык та такы - токыдыр инде хәзер. Һәрхәлдә яз ахырында гел шулай була иде бит инде...**

- Быел алай түгел. Былтыр һәр баш шартлы терлеккә 25,8 центнер күләмендә терлек азыгы хәзерләү безгә бүгенге көнгәчә малларны тулы кыйммәтле азыклар белән тукландырырга мөмкинлек бирә. Бозаулату алды һәм бозаулату бүлегендәге маллар өчен әлегәчә 7 килограмм печән, 4 килограмм катнашазык, 2 килограмм солы бирү мөмкинлегебез бар. Савым сыерларының рационы да тулы кыйммәтле булсын өчен тырышабыз без. Гомумән соңгы вакытта малларны асрау һәм ашату технологиясен төгәл үтибез.

**- Ә үрчем алу ничегрәк бара?**

- Шөкер, бозауларны салкын ысул буенча асрый башлагач, аларның үлем - китеме дә сизелерлек кимеде. Әйтик, быелның өч аенда алынган 124 баш бозауның барысы да диярлек исән - имин үстеләр. Хәер, монда малларны карачыларның да өлеше зур. Яшь терлекне эчәргә - ашарга өйрәтү үзе бер зур мәшәкать бит әле ул.

**- Шул җәһәттән, терлекчелектә уңышның нигезен тәшкил итүче кешеләр - мал караучыларның үзләре турында да берничә сүз әйтә алмассызмы икән?**

- Бик шатланып. Узган елгы көздән бездә терлекчеләргә, белгечләргә хезмәт хакын эшнең ахыргы нәтиҗәләре буенча түләү үткәрелә. Шуның нәтиҗәсе буларак, соңгы вакытта эшкә караш уңай якка үзгәрү сәбәпле аның нәтиҗәлелеге дә күтәрелде. Хәзер «миннән киткәнче» дип эшләүчеләр юк бездә, урлашып, кеше исәбенә яшәүчеләргә дә араларында урын калмады. Билгеле инде, бу факторлар да савымның артуына тәэсир ясамый калмагандыр, мөгаен. Әнә, уңган кызларыбыз Чулпан Бикиниева, Фәридә Дәүләтшина, Ралия Вәлитова группаларында бүген һәр сыердан уртача савым 12 - 13 килограмм тәшкил итә.

Киләчәккә исә планнарыбыз тагын да зурдан. Нәсел эшен яхшыртырга исәп. Быел нәселле таналар сатып алуны максат иттек. Малларның 100 процентын ясалма орлыкландыруны да киләчәк планы саныйбыз. Бу бурычларның барысы да кулдан килерлек. Аларны уңышлы хәл итү сөт терлекчелеген алга таба да стабиль үстерергә мөмкинлек бирәчәк.

**- Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт сезгә, Вәгыйзь Вазыйхович. Алга таба да уңышлар юлдаш булсын.**

**Әңгәмәдәш Р.ГИНЯЕВА.**

## Районыбызның хезмәт коллективларында

# Формасы үзгәрде, эчтәлеге - шул ук

**«Бентокам» ачык типтагы акционерлык җәмгыяте 1991 елда оешты. 1996 елның 15 маеннан гомуми җыелыш карары нигезендә ул ябык типтагы акционерлык җәмгыяте итеп үзгәртелде.**

«Бентокам» нигездә карьерны эшкәртеп, бентонит балчыгы һәм төзелеш материаллары җитештерү өчен балчык алуга йөз тота. Аның эшчәнлегендә тагы җирле һәм кайтартылган чимал ресурсларын файдаланып төзелеш материаллары җитештерү һәм сату, хезмәт күрсәтү, берөчтән торак төзелеше һәм промышленность объектлары төзү дә каралган. Әмма иң мөһиме булып кою производствосы өчен бентонит порошогы җитештерү һәм сату санала. Соңгысы илгә бик кирәк. Әлегә аны Греция, Израил, Болгария кебек илләрдән зур чыгымнар тотып кайтарталар. Үзебездә шушындый порошок җитештерү аны шактый арзанга төшерер иде. «Бентокам»ның генераль директоры И.И.Анискович хәзер шуны төрле югары дәрәҗәдә расларга, капиталь салым табуга ирешергә тырыша. Әйтергә кирәк, «Бентокам»ның планнары зурдан. Җәмгыять бентонитлы балчыкны чимал көе озатып зур табыш ала алмаячагын аңлый, шуңа да аны үзендә эшкәртүне максат итә, перспективада циклләп 4 завод төзүне планлаштыра. Беренчесе бентонит порошогы җитештерү буенча булса, икенчесе - керамзит, өченчесе - кирпеч җитештерү заводлары. Соңгы, циклны ябучы завод итеп кече йортлар ясау комбинаты булдыру ниятләнә. Әлбәттә боларны гамәлгә ашыру учредительләр - «КамАЗ», «ВАЗ», Чабаксар агрегат заводлары, «Березовское» фермер хуҗалыгы көченнән генә килерлек эш түгел. Өстәвенә, соңгы вакытта тимер юл тупигы белән дә авыр хәлдә калдылар. Карьер начальнигы урынбасары А.П.Гавритухин әйтүенчә, «Бентокам» элеккеге ДПМК тупигын 156 млн. сум түләп арендага алган иде. 2 ай эшләгәннән соң, ДПМК базасында УМС оештырылды да, барлыгы 56 милн. сум түләп акцияләрнең 60 процентына ия булып куйдылар. Шуның нәтиҗәсендә «Бентокам» чимал төяү планын өзде, бентонит көткән оешмалар чимал алып җиткермәделәр. Килешү буенча поставкалар сроклары да өзелде. Эшчеләрнең матди хәленә дә бу кире йогынты ясады. 8 ай буе хезмәт хакы бирә алмадылар, байтак әзерлекле кадрларын югалттылар. УМС 156 млн. сумны «Бентокам»га кайтарырга уйламый, тупик мәсьәләсе хәл ителмәгән көе кала.



*Таныш булыгыз: «Бентокам» акционерлык җәмгыяте шофёры Рамил Гыйрфанов. Ул биредә «Березовское» карьеры ачылган көннән бирле эшли. Тәҗрибәле, дисциплиналы шофёр нигездә карьердан чимал чыгару эшләрен үти, Гыйрфановның үз эшенә һич тел - теш тидерткәне юк, башкаручан, тырыш шофёрны коллективта тирән хөрмәт итәләр. Хәзер Рамил машинасын техник карауга әзерли.*

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

Әмма «Бентокам» яшәргә омтылышын җуймый. 32 кешене берләштергән, 4 экскаваторы, 9 КамАЗ машинасы, 3 бульдозеры булган коллектив хәзер карьерда тәҗрибә - промышленность эшкәртүләре алып бара. Киләчәктә икътисадый кыенлыкта үз - үзен саклап калу өчен Әлмәт заводы белән бәйләнешкә кереп «Березовское» карьеры чималыннан бентонит порошогы җитештерүне камилләштерүне максат итә. Порошок производствода кулланырлык сыйфатка җиткерелсә, аны сату базары табу кыен булмаска ошый. «Бентокам»га перспектив ниятләренә ирешкәнче яшәргә мөмкинлек бирергә тиешле чара итеп карала ул.

Күрәсез, җәмгыятьнең хуҗалык итү формасын үзгәртү аны проблемалардан арындыра алмый әле. Анысы, үзләре әйтүенчә, табышка ирешеп, аны акционерлар мәнфәгатендә файдалану максатында үзгәртелгән. Бу җәһәттән «Бентокам»нарның оптимистик рухларына сокланмый мөмкин түгел. Үзләре ышаналар икән, килер аларга табышка эшләячәк көннәр, килер.

**С.НУРУЛЛИНА.**

## Сезгә җавап бирәләр

**«Ачык хатлар көне»ндә район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин һәм службалары җитәкчеләре исеменә юлланган хатларга җаваплар урнаштыруны дәвам итәбез.**

# Быел да көтегез...

**Шәһәр Советы рәисе Ф.И.Гайнуллинга Дружба урамының 56 нчы барагында яшәүчеләр түбәндәге сорау белән мөрәҗәгать иттеләр: Иске йортларны сүтү турында закон бармы? Булса, бу закон нишләп безнең иске баракка кагылмый икән?**

«Норлатнефть» НГДУсы җитәкчелеге җавабыннан күренгәнчә (әлеге йорт НГДУ УТТсы балансында), әлеге баракта яшәүчеләргә УТТның 18 фатирлы торак йорты файдалануга тапшырылгач квартиралар бирелергә тиеш булган. Әмма финанс средстволары булмау сәбәпле, 1996 елда файдалануга тапшырыласы йорт төзелеше туктатылып торган.

«Йортны файдалануга бирү агымдагы 1997 елда планлаштырыла», - дип җавап бирә аларга иптәш Гайнуллин.

# Торак төзим дисәң...

***«Льготалы кредитлар кемнәргә бирелә, шул турыда язсагыз икән»***

**Р.Усманова.**
**Норлат шәһәре.**

Гражданнарга торак төзегәндә яки сатып алганда финанс ярдәме күрсәтү максатыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28 апрель 1995 елгы «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерү чаралары һәм торак реформасы турында»гы карары тарафыннан расланган Татарстан Республикасында торак формасы концепциясенә яраклаштырып, гражданнарга торак төзү яки алу өчен льготалы кредитлар бирү турында Положение эшләнде. Ул Положение түбәндәге пунктларны үз эченә ала:

1. Татарстан Республикасы бюджет средстволарын файдаланып торак төзү яки алу өчен льготалы кредитлар Татарстан Республикасында яшәүче, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ, закон нигезендә торак алу өчен чиратта торган һәм түбәндәге категорияләргә караган гражданнарга бирелә:

бюджет оешмалары хезмәткәрләренә;

«Ветераннар турында» федераль Закон нигезендә билгеләнгән категория гражданнарга;

яшь гаиләләргә (Татарстан Республикасының «Яшьләр турында» Законына яраклаштырып);

гамәлдәге законнар нигезендә Республика бюджеты средстволарыннан торак төзелешен яки алуны льготалы финанслауга хакы булган, әмма аны кулланмаган кешеләргә;

2. Татарстан Республикасы бюджет средстволарыннан торак төзелеше яки аны сатып алуга льготалы кредит алучылар торак шартларын яхшыртуга учеттан төшереләләр.

3. Льготалы торак кредиты гражданнар тарафыннан аларның теләге буенча файдаланыла;

- алар сайлавы буенча әзер торак алуга;

- шәхси торак йортны үтәлгән эш күләменә күчереп түләү рәвешендә финанслауга;

- квартираны күп фатирлы йорт төзелешендә өлешчә катнашып төзегәндә финанслауга;

4. Льготалы торак кредиты гаилә члененың һәрберсе өчен 18 кв.м. социаль норма күләменнән исәпләнгән гомуми мәйданны төзү өчен кирәкле средствоның 70 проценты күләмендә бирелә.

5. Льготалы торак кредиты гражданнарга баштагы ике елга процент исәпләүләре түләүне кичектереп, 15 елга бирелә.

6. Татарстан Республикасы бюджет средстволарыннан льготалы торак кредитлар елына 5 процентлы ставка белән бүленәләр.

7. Процент ставкасы Россия Федерациясе Үзәк банкы учет ставкасы һәм акча базары конъюктурасы үзгәргәндә шулай ук үзгәрергә мөмкин.

8. Льготалы торак кредитлары бирүгә хокуклы итеп Россия Федерациясе Саклык банкының Татарстан банкы санала.

## Тирәбездә яхшы кешеләр

# «Син сау булсаң - без дә сәламәт»

Рамилә үзенең беренче эш көнен әле дә елмаеп искә ала. Түбән Кама медицина училищесын тәмамлагач, иптәш кызы Зоя белән икесен үзләренең Балык Бистәсе районы Корноухово участок шифаханәсенә эшкә билгеләделәр. Баш шәфкать туташы, соңыннан аңлашылганча, үтә дә кырыс, таләпчән Зоя Александровна кызларга кире каккысыз тавыш белән беренче эшне кушты.

- Менә бу абзыйга катетр куегыз.

Ничекинде, алар, эрен кебек кыз балалар, оялмыйча - тартынмыйча бу эшне башкарсыннар? Зоя елады, кычкырды, кулларын селтәде дә китеп барды. Авыртудан интеккән авыру белән Рамилә калды һәм кыенсынуын басып, ихтыярын җыеп, медсестра кушканны җиренә җиткереп үтәп тә куйды... Зоя Александровна моны әлләни батырлыкка санамыйча, янә эш кушты:

- Авыруга система куярга. Менә күрсәтмәләре. Мин китәм.

Анысын артык җәфаланмыйча башкарган гына иде Рамилә, авыру калтырана башлады. Кыз куркынып, тизрәк тәҗрибәле шәфкать туташына йөгерде.

- Авыруга реакция кергән. Туктат тамчы бирүеңне, - дип резина көпшәләрне бергәләп җыештыргач, Рамилә үзенең никадәр җаваплы эшкә алынганын тоеп, хәлсезләнеп урындыкка утырды.

Соңрак Балык Бистәсе шифаханәсендә 3 ел үсмерләр шәфкать туташы булганда да, 8 ел «Ашыгыч ярдәм» машинасында фельдшер булып эшләгәндә дә ничәмә - ничә тапкыр иң кыен, иң билгесез, иң катлаулы очракларда да шушы тәүге чирканыч алган көнен искә төшереп тәвәккәллек җыя иде ул. Ул вакытка инде кыз яхшы аңлады: медицина хезмәткәренең оялырга да, тартынырга да, куркырга да, икеләнергә дә хакы юк. Аңа кеше үзенең иң кадерле нәрсәсе - тормышын ышанып тапшыра. Кайчак ул иң киеренке чиккә җиткән була, бары шәфкать туташының үз вакытында күрсәткән дөрес ярдәме генә кешенең гомерен саклап кала. Соңгысына Рамилә «Ашыгыч ярдәм» дә эшләгәндә аеруча нык инанды. Уланда үзе генә, врачсыз йөри иде. Авариямe, катлаулы башка очракмы - иң беренче карарны аңа кабул итәргә туры килә иде. Кешеләр белән уртак тел табарга, аларны сүз белән дәваларга да шунда өйрәнде ул. Кулы йомшак, әмма нык, теле ягымлы, ышандыручан, хәрәкәтләре ипле, җитез фельдшерны ары таба 2 еллык курсларга барып белемен дәвам итәргә өндәделәр. Әмма язмыш бөтенләй башкача борылды - Рамилә Балык Бистәсеннән Каманың бу ягы - Октябрь районының Колбай Мораса авылына Рамил Дәүләтбаев дигән егеткә кияүгә чыгып куйды.

(Ахыры 3 нче биттә).


## Акцияләр сатып алабыз:

### «Газпром» РАҖ,

**«Сургутнефтегаз» АҖ,**
**«ЛУКойл» НК АҖ,**
**«Татнефть» АҖ,нең (Б категорияле),**
**«Ноябрьскнефтегаз» АҖ,**
**«Юганскнефтегаз» АҖ,**
**«Пурнефтегаз» АҖ,**
**«ЕЭС России» РАҖ**
**акцияләрен сатып алабыз.**

***Бәяләр - иң кыйммәте.***

Адрес: Совет ур., 94, тел.: 2 - 23 - 10, 2 - 18 - 61, (эш көннәрендә иртәнге 8дән кичке 5кә кадәр). ТР финанс министрлыгыннан бирелгән 72 нче номерлы лицензия.

## Авыл: кичә. Бүген. Иртәгә.

# БАШЛАНГЫЧЫ БАР

Районда башка күп кенә хуҗалыклар белән беррәттән соңгы елларда Әлмәттә дә хәлләр шәптән түгел. Ассоциация рәвешендә яши башлагач та тулаем алганда производствоның җитештерүчәнлеге дә артмады, нәтиҗәдә халыкның социаль яшәеше дә яхшырмады. Дөрес, үткән елгы күрсәткечләргә караганда игенчелектә Әлмәт өчен зур күтәрелеш бар, колхоз тарихында беренче тапкыр бөртеклеләрне гектарыннан 23 центнер алуга ирешкәннәр. Шикәр чөгендере дә әйбәт кенә - гектарыннан 239ар центнер чыккан. Аның каравы, терлекчелектә планнар 20 - 30 процентка үтәлмәгән. Быел исә үткән елгы уңыш нигезендә сыйфатлы терлек азыгы, җитәрлек дәрәҗәдә печән, концентратлар булуы үз эшен итә: сөт җитештерү район буенча уртача күрсәткечтән шактый түбән булса да, былтыргы күрсәткечтән югарырак та, сыйфатлырак та. Бозаулар үлеме азайган.

Ләкин бу уңай нәтиҗәләр, әлбәттә, чишелмәгән гомуми проблемалар алдында юкка тиң. Бүгенге көндә хуҗалык кассасына керем бердәнбер продукция - сөт сатудан килә. Анысы да башлыча салымнарга, хуҗалыкның төрле вак - төяк чыгымнарына китеп бара, шуңа күрә хезмәт хакын түләү һаман кичектерелә: үткән елгы 230 миллион сум бурыч әле түләнмәгән. Ә алда язгы кыр эшләре җәелеп ята, ничәгә генә ярылсаң да таушалган иске техниканы, бигрәк тә тракторларны ремонтлауда зур кыенлык кичерәләр. Ягулык - майлау материалларына кытлык исә барлык көндәлек эшләргә дә тоткарлык тудыра, хәтта бензин булмау сәбәпле сөтне комбинатка илтә алмый аптыраган чаклары да еш була...

Кыскасы, эшләр шулай дәвам итсә, хуҗалыкта хәлнең уңайга үзгәрәсенә өмет тә күренми.Һәм шуңа күрә әлмәтлеләргә дә бөтен республикада башланган реформалау юлына басудан бернәрсә дә югалтмауларын аңлавы кыен түгел иде. Шул хакта ачыктан - ачык сөйләшүгә җыйналган халык үзгәрү, җир кадәр җирне үз җилкәңә, җаваплылыгыңа йөкләүнең авыр икәнлеген төшенсә дә, еллар буе күпме продукция җитештереп тә мантый алмагач башка юл белән яшәп карарга кирәклеген тирәнтен аңлый иде булса кирәк. Җыелышта шул фикер кызыл җеп булып үтте. Тирәнтен үзгәреш халык аңында эчке борылышның асылы, гади итеп әйткәндә, колхозчының элеккечә, колхозныкы - безнеке дип түгел, минеке дип ахыр нәтиҗәгә эшләвене ирешүдән, ягъни аны милекче, милек - мөлкәткә чын хуҗа итүдән гыйбарәт.

- Әлбәттә, әле аңлап җиткермәүчеләр, бигрәк тә ышанып бетермәүчеләр дә юк түгел,-ди хуҗалыкның баш экономисты Җәүдәт Хәйруллин. - Тамырдан үзгәреш бер кизәнү белән генә гамәлгә ашырылмый.

Әлмәт мисалында реформа болай башланды: элеккеге бригадалар нигезендә өч кооператив оешкан. Аларның икесенә механизаторлар Илдус Сабиров һәм Исмәгыйль Нуретдинов, өченчесенә агроном Рамил Вафин әйдәүче булып сайланалар. Остаханә, запас частьләр складлары, такта ярдыру цехы, һәртөрле ярдәмче биналар хезмәт күрсәтүче кооперативны тәшкил итәчәк дип хәл ителде. Аңа җитәкче итеп Рәис Исмәгыйлев сайланды. Өч кооперативтагы 676 кешегә исәпләп 5әр гектардан артык җир пае бүленде, терлекчелек абзарлары, маллар беркетелде. Аларга хокуклы барлык халыкның 230ы гына хуҗалыкта даими эшләүчеләр (калганнары - пенсионерлар). Шуларның 80 процентка якынына бүгенге көндә «Җир кишәрлегенә милекчелек хокукы» һәм «Мөлкәткә хокук турында» таныклыклар тутырып алардан кооперативка кабул итү хакында гариза язылган. Шулай итеп, кәгазьдә алар милекчегә әйләнгән. Хәзергә шикләнебрәк калганнарга да иртәме, соңмы, барысын да үлчәп бер агымга, беренчеләр үрнәгенә ияреpгә туры киләчәк, чөнки 5 гектарлап җире белән ялгыз калып, аны эшкәртеп, иген үстереп җыярга мөмкинлеге булган игенче әлегә күренми.

Менә шулай Әлмәттә реформалау юнәлешендә әйбәт кенә оештыру эшләре алып барыла.

«Дөрес, кыенлыклар да, бигрәк тә исәп - хисап өлкәсендә буталчыклар, киртәләр бихисап»,- ди баштанаяк реформа мәсьәләләренә чумган баш экономист.

Тамырдан үзгәртеп кору рухы белән бергә агымдагы эшләрне дә игътибар үзәгендә тоталар: авыл хуҗалыгы техникасы язгы кыр эшләренә әзерләнә, сөрү җирләренең гектарына физик авырлыкта 274, тәэсир итүчән матдәгә әйләндергәндә 82шәр килограмм ашлама кайтарылган, терлекчелекнең артта калган дуңгызчылык тармагында каплату эшләренә, ниһаять, ныклап керешергә ниятләгәннәр.

Алга таба ни көтәсен фараз итү кыен әле. Реформа билгеләре кәгазьдә генә түгел, асылда беленә башлагач күренер анысы. Әллегә шунысы мөһим - үзгәрешнең башлангычы бар инде.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

# ЧӘЧҮ АЛДЫННАН - «УРАК ӨСТЕ»

**Гөлләр тулы якты, җылы бу бинада ниндидер бер эшлекле тынлык беркайчан бетми диярлек. Ак халатлы хатын - кызлар пинцетларын җитез - җитез йөртәләр, нидер үлчиләр, язалар, теркиләр. Ә беренче катта тезеп куйган формаларда дөньяга быелгы язның беренче шытымнары борын төртә.**



Район дәүләт орлык инспекциясендә кызу көннәр бүген: чәчүлек материалны чәчү алды тикшерүе бара. «Чәчү алдыннан «Урак өсте», диләр кызлар үзләре. Барлык хуҗалыклар орлык үрнәкләрен тикшерүгә китергәннәр, алар орлыкның тишелешенә тикшерү узганнар инде.

- Шатланып әйтә алабыз: кышкы чорда орлыкларның шыту сәләте кимемәгән, коры килеш салганлыктан орлыклар әйбәт сакланганнар,- диләр инспекция хезмәткәрләре.

Алары - «Знамя Октября» һәм «Чишмә» КХАлары икән. Бу хуҗалыкларның орлыклары көздән үк түбән сыйфатлы, кондициясез булуы күзәтелгән. Аларны өстәмә эшкәртү өчен озын көз, кыш буе вакыт булса да, тегеләре аның белән шөгыльләнүне кирәксенмәгәннәр, күрәсең: орлыклары янә сыйфатсыз...

Инспекциядә гомумән районга кергән һәр орлык тикшерү үтә. Ел дәвамында хатын - кызларның җитез куллары, игътибарлы тикшерүе аша 3 меңнән артык орлык үрнәге уза. Хәзер әнә ихтыяҗдан чыгып читтән орлыклар кайтарыла. Яңа Чишмә районының «Кызыл Октябрь» колхозыннан, «Столбище» тәҗрибә - җитештерү хуҗалыгыннан кайтартылган элита бодай, борчак орлыкларын тикшерделәр, алары да сыйфаты ягыннан озатучы документларына тәңгәл киләләр. Инспекция хезмәткәрләре әнә шулай уңыш прогнозы турында беренче мәгълүматларны ачыклыйлар. Дөрес, икмәк дигән галиҗәнап ризык муллыгы күп факторларга бәйле. Әмма барыбер аның нигезен сәламәт, нык, әйбәт орлык тәшкил итә. Шуңа да хезмәткәрләр орлыклык материал турында иң төгәл мәгълүматны бирергә, җиргә күмгәнче аның сыйфатын яхшыртуга ирешергә тырышалар. Нина Михайловна Бабушкина белән Фәния Мингалимовна Шәкүрова - шушы эш 20 елдан артык гомерләрен багышлаган хезмәткәрләр. Нина Михайловна техник - лаборант булса, Фәния Мингалимовна - өлкән лаборант, ул читтән торып Саратов авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган белгеч. Сабыр, ипле холыклы, зур тәҗрибәле хатын - кызлар коллективның башка әгъзалары төсле үк бүген бар игътибарларын өстәл өстендәге өмет бөртекләре - орлыкларга юнәлткәннәр. Гөлләр тулы якты, җылы бинада янә эшлекле тынлык...

**С.НУРУЛЛИНА .**

**Рәсемдә: Норлат орлык инспекциясе хезмәткәрләре Н.М.Бабушкина, Ф.М.Шәкүрова.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

# «СИН САУ БУЛСАҢ - БЕЗ ДӘ СӘЛАМӘТ»

**(Ахыры. Башы 2 нче биттә).**

Бирәдә аны авыл медпунктына акушерка итеп билгеләделәр. Морасалылар - теләсә кемгә йөрәген - җанын ачарга ашыкмый торган талымлы, сынаучан халык. Яшь киленнең җил - җил атлап эшләп йөрүен, авыруларның моң - зарын тыңлый белүен, уколны ипле кадавын, әйбәт - әйбәт киңәшләр, билгеләүләр ясавын, көн - төн белән исәпләшмичә авыру чакыруына йөгерүен күргәннән соң гына аны үз кеше санап ярата башладылар.

Әмма шул көннән аңа һич җил - яңгыр тидермәслек итеп ярата, иң яшерен серләрен сөйли, сүзләрен бүлешә торган булдылар да куйдылар. Пунктта алар өчәү эшлиләр: мөдир Гөлсинә Галиуллина, физкабинет сестрасы Гөлсирә Мингалимова. Һәрберсе үз урынында әйбәт белгеч, намуслы хезмәткәр, ә шулай да Рамилә килгәч медицина хезмәткәре дәрәҗәсе кайчандыр авылның данлыклы, кырыс «врачлары» Пелагея Ивановна Фролова, Шакирә Мәхмүтова чорындагы хөрмәтле дәрәҗәгә күтәрелде. Ярты гасырга якын авылга хезмәт иткән кырыс та, гадел дә, үтә белемле дә бу ханымнарга халык туун да, яшәвен дә, әхлагын да тулысынча ышанып тапшырган иде. Рамиләдә шул сыйфатларны таптылар. Ул йомшаграк сүзле, иплерәк, җайлырак та. Акушерка буларак, һәр елны 13 - 14 яшь сабыйның туганчы һәм тугач сәламәт үсүен кайгырта ул. «Яшь ана мәктәбе»ндә хатын - кызларга ана булу, бала тәрбияләүнең беренче адымнарын өйрәтсә, авылның хатын - кызлар советы әгъзасы буларак гаилә, мәктәп, җәмгыять мөнәсәбәтләренә кагылышлы иң катлаулы очракларны хәл итүдә дә катнашырга туры килә аңа. Медпунктта исә алар һич кенә дә эш бүлешмиләр: көне - көне белән Рамиләгә дә 40ар кешене кабул итәргә, уколлар ясарга, киңәшләр - дарулар бирергә туры килә. Каты авыруларның өенә барулары, көндезге - төнге чакыруларны да өстәсәң... Авыл фельдшерына бит акушерка да, терапевт та, стоматолог та, хәтта хирург та булырга туры килә. Менә кайда ярап куйды Рамиләгә «Ашыгыч ярдәм» тәҗрибәсенең ярдәме! Авыруның хәленнән чыгып, һәрчак дөрес адымны ясый белә ул. Әнә Халидә апа Тукаевага ишемик инсульт булгач та участок шифаханәсеннән ярдәм килгәнче авыру баш очында алар тордылар. Өйдә 5 тапкыр бала кабул итәргә туры килде үзенә (бу хәл макталмый, әмма тормыш бит гел без дигәнчә түгел!). Иң кыен чакта Иске Әлмәт участок шифаханәсе хирургы В.Д.Симцов белән киңәшә. Исең китсен: Вячеслав Дмитриевич һичкайчан иренми, ашыкмый һәм ялгышмый. Рамилә дә иренә, авырсына торганнардан түгел. Авылда 6 ел эшләү дәверендә бер концерт, спектакльне дә бүленмичә ахырынача карый алганы, бер кичне дә «вызов»ка бармый калганы юктыр, мөгаен. Нишлисең, авыру тилмереп сине көткәндә, үз кәефеңне уйлап торасың димени? Ярый, өендә ире дә, кайнанасы да аңлыйлар хезмәтенең бу якларын. Ә авыл халкы аны рәхмәт сүзләре белән күмә. Һәр көнне аларны ничәмә - ничә дистә кешедән ишетә, очрашкан саен һәр авыл кешесенең хөрмәтен тоеп җаны җылына аның. Бәлки, шуңа туган якларын сагынуы басылып киләдер дә? Бәлки, кызы Лилия дә шуның өчен әнисе һөнәрен сайларга телидер? Рамилә үзе елмая: ай - һай, булдырырмы, сабырлыгы җитәрме?.. Шәфкать туташы өчен иң мөһиме сабырлык, иплелек, кеше хәленә керешә, аңлый белү бит. Иң мөһиме - битараф калмау. Әнә авылда авыр матди хәлдәге А. гаиләсендә үскән 4 яшьлек малайга пенсия билгеләтү өчен йөрү һич кенә дә акушерка вазифасына керми иде юкса. Гаиләнең хәлен күреп йөрәге түзмәде, барыбер очлап чыкты Рамилә. Шундый җаваплылык аны эшендә дә, яшәвендә дә дәрәҗәле итә инде. Һәр көнне, авыл урамына чыгып басуга, олысы - кечесе кояш кебек елмаеп аңа сәлам бирә:

- Исәнме, Рамилә кызым!

- Исәнмесез апа.

- И, наныем, исән - сау гына була күр! Син исән - сау булсаң - без дә сәламәт булырбыз.

**С.Хәйруллина.**

# Мәдәни тормыш мизгелләре

## Безнең кунакханә

**Фирзәр Мортазин. Талантлы композитор һәм жырчының «стажы» 20 ел булган икән инде. Шушы чорда аның таланты үсеш алды, исеме популярлашты, үзе Татарстанның атказанган артисты» исеменә лаек булды. Норлатка һәр килүендә Фирзәрнең таланты камилләшүен, репертуары үзгәрүен, профессиональлеге артуын билгелибез без. Жырчының безгә соңгы килүендә дә без аның белән шул хакта сөйләштек.**

## «ҮЗЕМ БУЛЫП КАЛАСЫМ КИЛӘ»

### Редакция кунакханәсендә - жырчы һәм композитор Фирзәр Мортазин

- Күптән түгел без эшли торган «Салават» жыр театры студиясе минем беренче ижат жимешем - Рәшит Сабировның «Ява карлар» дип аталган шигыренә көй язуыма 20 ел тулуны билгеләп үтте. Дөресен әйтим, бу тәүге жырым минем өчен балам кебек кадерле. Ни өчен дигәндә, мин ул вакытта бик яшь, әле 20не дә тутырмаган идем.

**- Бүгенге көндә ничә жыр авторы булып торасың?**

- Озакламый минем жырларым язылган китап дөнья күрәчәк. Анда шагыйрьләрнең фоторәсемнәре дә урын алачак, алар турында мәгълүматлар да булачак. Анда шушы ике дистә елда ижат ителгән 80ләп жырымның барысына да урын биреләчәк.

**- Аларның байтагы кайсы елларга туры килүен исеңә төшерә алмассыңмы?**

- Көй язу ижади эш бит ул. Мин үзем шигырьләр укырга бик яратам. Кайчак шигырь укыганда ук күңелдә көй туа. Кайчак «менә сиңа шигырь - шуңа көй яз әле» дип заказ бирәләр, ә көйне язып булмый. Ә күңелдә көй тумаса, аны үзеңне үзең мәжбүр итеп кенә язып булмый. Ижади эшнең төп асылы да шунда.

Якынча исәпләвем буенча, ел саен мин уртача 4 жыр язам. Кайбер еллар «жимешлерәк» була, икенчеләре - киресенчә.

**- Фирзәр, Норлатка бу килүеңдә репертуарың ничектер үзгәреп, житдиләнеп киткән. Моңа бер - бер сәбәп бармы әллә?**

- Хәзер бит жырчылар күп. Аңлашыла ки, конкуренция дигән нәрсә без жырчылар ижатына да кагылышла. Шуңа да мин концерт программаларымны бер жырчыны да кабатламаслык итеп төзим. Икенче төрле итеп әйткәндә, һәрчак үзем булып каласым килә.

**- Группагызда да үзгәрешләр бар бугай...**

- Әйе. Хәзер ул нигездә Мортазиннардан тора. Ике еллап элек Буада «Ләззәт» ансамбле составында чыгыш ясаган энем Илсур белән аның хатыны Мәүлидәне дә үз коллективыма алдым. Энем Илсур - рәссам. Ул безнең концертны алып бара, үзен жыр сәнгатендә сыный. Мәүлидә мәдәният институтын бетерде, белгечлеге буенча хор житәкчесе. Ул безнең жырчыбыз. Кече Мортазиннар безнең ижат коллективы тормышына жиңел кереп киттеләр, халык та жылы кабул итә үзләрен.

**- Жырчы, композитор Фирзәр Мортазин ижат группасы житәкчесе генә түгел, гаилә башлыгы да бит әле...**

Әйе, әмма өйдә сирәк булуым «башлык» ны тормышта ласларга мөмкинлекне күп бирми шул (көлә). Сәхнә кешесенең байтак гомере юлда үтә бит. Шуңа да «башлык» вазифасын еш очракта хатыным Наиләгә үз жилкәсенә алырга туры килә. Миңа байтак очракта тәэминатчы роле генә кала. Шөкер, шулай кем баш, кем муен булырга тиешлекне бүлешмичә яшәвебезгә быел августта 20 ел була. Кызым Чулпан үземнең юлны сайлады. Мәдәният һәм сәнгать академиясенең хор бүлегендә II курста укый. Улым Ленар да жыр - музыкага гашыйк. Мәктәптә, 7 нче сыйныфта укый, берүк вакытта балалар музыка мәктәбендә дә белем ала. Сәхнәдә дә чыгыш ясый.

**- Киләчәккә планнарың...**

- Группабыз белән яңа альбом яздырабыз. Китап турында алда әйттем бит инде. Киләчәктә дә жырлар язып, жырлап яшәргә исәп. Әле менә Норлатның визит карточкасы булырлык бер жыр язасы килә.

**- Махсусмы?**

- Әйе, мин Норлат тамашачысын бик яратам, үз итәм. Халык бик гади, ихлас күңелле биредә. Алар алдына чыгуга сәхнә белән зал арасында үзенчәлекле жылы мөнәсәбәт урнаша. Жырлыйсы да жырлыйсы гына килеп тора инде мондый чакта.

**- Шулай булгач, күңелеңдә көи туасына да ышанычыбыз ныклы. Сиңа ижат уңышлары, хәерле юллар һәм... бездәге кебек ихлас тамашачылар телибез.**

**Әңгәмәдәш - Р.ГИНЯЕВА.**

# ХАЛИСӘБЕЗ КАЙТЫП КИТТЕ

Халисә кайткан... Халисәбез дә килә икән Фирзәр белән дигән хәбәр авылда яшен тизлеге белән таралып өлгерде.

Мәшһүр биюче Халисә ханым Шәрәпованың туган авылы Киеклегә һәр кайтуын авылдашлары зур шатлык, олы горурлану хисе белән кабул итә.

Сәнгать осталары белән очрашу мәктәп бинасында билгеләнгәнгә күрә, авылның олысы да, кечесе дә шунда агылды бу кичне. Урын тыгыз, матур итеп бию өчен, беренче карашка, шартлар да юк төсле. Ләкин үзебезнең илнең генә түгел, ә бик күп чит илләрнең сәхнәләрендә дә якты йолдыз булып балкыган Халисә ханым мәктәп коридорларында да һәркемне таң калдырырлык итеп бии ала икән. Ә моңа бары тик чын сәнгать остасы гына сәләтле. Татар, төрек, башкорт, чегән кызы, каенана биюләре - төрле темптагы бию үрнәкләре. Ул аларның һәркайсын зур осталык белән башкарып кына калмый, ә тамашачыларга һәр биюнең үзенә генә хас булган асыл сыйфатларын тоемларга, күрергә булыша. Шуңа да Шәрәпова тудырган дәрт тулы, хисләр ташып торган, эчке янулы образлар бер - берсен кабатламый. Һәр яктан камилләшкән, үз эшенең остасы Татарстанның атказанган артистлары Халисә ханым Шәрәпова барлык борчу - мәшәкатьләребезне онытырып, рәхәт ял минутлары бүләк итте безгә бу кичне, чын сәнгать үрнәкләре белән таныштырды. Рәхмәт сиңа, Халисә, рәхмәт якташыбыз.

**Ф.ВӘЛИУЛЛИНА.**
**Киекле авылы.**

## Кичәге почтадан

# КҮҢЕЛЛЕ ЯЛ ИТТЕК

Соңгы елларда авылыбыз үзешчәннәренең сәхнәдә сирәгрәк чыгыш ясауларына күрәдер инде, халык концерт - спектакльләрне зарыгып көтеп ала. Сайлаулар көнне концерт була дигән хәбәр дә авылның барлык халкын мәдәният йортына жыйды. Һәм үзешчәннәребез авылдашларын күнелле ял иттерделәр. Түбән Норлат урта мәктәбенең VIII сыйныф укучысы Фирдүс Тәмаев жыр белән концертны башлап жибәрсә, укытучы Фәридә Әхмәдиева халык биюләрен зур осталык белән тамашачылар күңеленә хуш килерлек итеп башкарды. Венера Куляева, Рузалия Гомәрова, Мөнәвәрә Ольнова, Сиринә Халитова, Резидә Тәмаевалар жырлый башлагач тамаша залы аеруча жанланып китте. Жырның сихри көче барысын да үзенә тартты. Фердинанд Ильмухин музыка коралларында бер үзе уйнаса да, арыганын сиздерми, һәр башкаручының үз тавышын, үз моңын тоеп көйне тыңлаучыларга чын осталык белән житкерә. Ә мәдәният йорты мөдире Эфрузия Тәмаева үзе үк концертны алып баручы буларак, үзешчәннәр белән уртак тел табып, концертны югары дәрәжәдә оештырды.

**Тәзкирә АЛЯКИМОВА.**
**Түбән Норлат.**

## Шахмат Шахмат

# Быел да Ринат чемпион

Ирләр арасында шахмат буенча шәһәр беренчелегенә шәхси - команда ярышлары тәмамланды. Ринат Миңнебаев быел да чемпион исемен үзендә калдыруга иреште. Хәер, баштан ук һәр партиясен жиңү белән тәгәлләп килгән, турнирның икенче яртысында тагы да зуррак ыргылыш ясаган остаһың быел да батыр каласына һичкем шикләнмәде дә.

Сергей Анисимовның уены да игътибарга лаек. Актив һәм һөҗүмчән шахматчы ул. Тик бу чемпионатта күп кенә матур ниятләрен ахырынача житкерә алмады. Әмма аның яулыйсы үрләре алда әле.

Н.Фатыйхов Сергей белән икенче урынны бүлеште быел. Ә.Гыйльманов, В.Членов, И.Крылосов иң көчле алты шахматчы рәтенә керделәр.

Команда беренчелегендә урыннар түбәндәгечә бүленде: НГДУ, «Локомотив» (тимер юл), «Сельхозтехника» берләшмәсе.



Чемпионат тәгәлләнеп, жиңүчеләргә дипломнар, мактау кәгазьләре, истәлекле бүләкләр тапшырылганнан соң, чемпион берьюлы берничә тактада уйнау осталыгын күрсәтте.

**А.КОСТИН.**

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Биккол авылында яшәүче **Минзифа Шакир** кызы **Шәйхетдинованы** 70 яшьлек юбилее белән котлыйбыз. Әниебезгә озын гомер, исәнлек телибез.



**Жәрия, Минәхмәт, Миния, Ленар, Әлфис, Роберт.**


## Белдерүләр

### Сатабыз

**Москвич - 2140.** Адрес: Совет ур., 104 - 14 (кичке 5тән соң).

***

**6,5 х 10 метрлы бура, 1990 елгы «Днепр» мотоциклы, әйбәт хәлдәге ГАЗ - 24 автомобиле. Бәяләре килешү буенча**. Тел.: 2 - 22 - 55.

***

**Бозаулаган сыер**. Мамык авылында инкубаторга яки 4 - 12 - 41 телефоны буенча мөрәжәгать итәргә.

***

**2 бүлмәле фатир (54,6 кв.м.).** Адрес: Кузнецов ур., 2 - 2 (кичке 5тән соң).

***

**1994 елгы ВАЗ - 2106, ГАЗ - 53кә япма (тент), «Термекс» газ казаны**. Адрес: Западный бистәсе, 48 нче позиция.

***

**Линейная урамында гараж урыны (нигезе, капкасы, базы бар).** Аксумла авылында Сергей Михайловка мөрәжәгать итәргә. Тел.: 3 - 62 - 37.

***

**Дача участогы, «Свияга» суыткычы (кабында), койма челтәре.** Тел.: 5 - 18 - 71.

***

**Яңа «Урал» мотоциклы**. Тел.: 2 - 19 - 75 (кичке 5тән соң).

***

**Нефтьчеләр урамында бер бүлмәле фатир.**
Тел.: 5 - 25 - 36.

***

**Стенка. Кыйммәт түгел.** Адрес: К.Маркс ур. 4 - 23.

***

**Шәһәр үзәгендә бер бүлмәле фатир**. Тел.: 5 - 20 - 00.

***

**«Альянс» кибете (колхоз базары) шәһәрдәге иң арзан бәяләрдән Аксубай һәм Октябрь районнарында өстәмә түләүсез өйгә китереп бирү шарты белән 1, 2, 3 камералы «Стинол», «Минск», «Норд» суыткычлары, каты һәм сыек ягулык белән эшли торган газ мичләре (су да жылыта торганы - 2 млн. сум, су жылытусызы 1 млн. 550 мең сум) сата.**

Жентекле мәгълүматны «Альянс» кибетеннән, яки 5 - 24 - 97 телефоны буенча белешергә мөмкин.

Лицензиябез сер. А - 96 № 007075/1.

### Алмаштырабыз

**Шәһәр уртасындагы 2 бүлмәле фатирны - бер бүлмәлеләргә.** Тел.: 5 - 26 - 03.


### Белмәдек димәгез!

«Надежда» дәүләт предприятиесе (КБО) ремонтланган телерадиоаппаратураларны мастерскойдан шушы белдерү басылып чыкканнан соң бер ай эчендә килеп алырга кирәклеге, соңыннан мастерскойның жаваплылыкны үз өстеннән төшерүе турында кисәтә.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ЖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның сишәмбе, жомга көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәржемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хужалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм жәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәржемә буенча мөхәррир - 2-10-44, жаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәржемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2089 данә. 6572